Сунь-цзы

СУГЫШ СӘНГАТЕ

Тәрҗемәче һәм туплаучы Айдар Шәйхин

Казан
Яңа нәшрият
2018

Сунь-цзы.

Сугыш сәнгате / Сунь-цзы ; тәрҗ. һәм төз. А.Шәйхин. — Казан : Яңа нәшрият, 2018. — 48 бит.

Борынгы Кытайның бөек сугыш остасы Сунь-цзы бихисап дошманнарын да җиңгән, җиңүләренең серен тасвирлап, хәрби трактат та язып калдырган. 2500 ел элек иҗат ителгән китапны әле хәзер дә хәрбиләр, тарих белән кызыксынучылар, Кытайны сөючеләр һәм заманабызның көндәлек бәрелешләрендә – бизнес дөньясында – җиңүгә омтылган эшмәкәрләр укый. Хәзер хәрби стратегия һәм сәясәткә багышланган борынгы Кытай трактаты татар телендә дә дөнья күрде.

© А. Шәйхин, тәрҗемә һәм әзерләү, 2018
© Бизәлеш. «Бук» ҖЧҖ, 2018

СУНЬ-ЦЗЫ ҺӘМ АНЫҢ «СУГЫШ СӘНГАТЕ»

Сунь-цзы (остаз Сун) — Кытай хәрбие, сугыш стратегы, язучы һәм фәлсәфәче. Ул борынгы Кытайның Көнчыгыш Жу чорында яшәгән. Чын исеме Сун Ву булса да, замандашлары аны Чжанцин дип атаганнар. Ә инде Аурупа дөньясына таныш булган «Остаз Сун» — «Сунь-цзы» исеме аны ихтирам итүнең бер билгесе.

Сунь-цзының төгәл кайчан яшәгәне мәгълүм түгел. Гадәттә, аның тормыш елларын безнең чорга кадәр 544—496 елларга туры килгән дип билгелиләр. Ул чорларда Кытай бихисап вак патшалыкларга һәм морзалыкларга бүленгән булган. Сунь Ву Янцзы елгасының түбән агымында урнашкан У патшалыгында стратег һәм сәргаскәр вазыйфасын биләгән. Кытайда тарихи чорларнын үзенчәлекле бүленеше бар, менә шул бүленеш буенча, Сунь-цзы яшәгән вакыт Язлар вә Көзләр дәвере (б.ч.к. 770—476 еллар) белән Сугышучы патшалыклар (б.ч.к. 475—221 еллар) дәвере арасына туры килә. Бу елларда Кытайда җиде дәүләт башка җирләргә хуҗа булыр өчен аяусыз көрәш башлый. Аңлашыла ки, мондый катлаулы гасырда гаскәрләрнең куәте һәм гаскәр башлыкларының хәрби осталыгы сынала да инде.

Сунь-цзы язып калдырган «Сугыш сәнгате» исә борынгы дөньяның иң күренекле әсәрләренең берсе. Асылда, ул стратегия, тактика һәм идарә теориясе турында системалы һәм җентекле белешмәлек булып тора. Китап дәүләт яки гаскәр башлыгын төрле шартларны дөрес кулланып, сугышта җиңүгә ирешергә өйрәтә. Борынгы Кытай тарихында бу трактта әйтелгән идеяләргә күп тапкыр мөрәҗәгать иткәннәр. Гомумән, бөтен Көнчыгыш Азиядә «Сугыш сәнгате»н хәрби җитәкче булырга теләгән һәр кеше белергә тиеш булган. Япон илендә XVI гасырда яшәгән дайме Такеда Шинджен, риваятьләргә күрә, «Сугыш сәнгатен» укып өйрәнгәч, бер бәрелештә дә җиңелмәгән диләр. XX гасырда кытай инкыйлабчысы Мао Цзэдунның хәрби стратегиясенә дә Сунь-цзы йогынты ясаган. Вьетнам сугышында катнашкан кайбер Вьетконг хәрбиләре «Сугыш сәнгатен» яхшы белгән, хәтта аны яттан сөйли алган. Америка Кушма Штатларының Армия министрлыгы исә һәрбер хәрби бүлекчәнең китапханәсендә бу китап булырга тиеш

дигән карар чыгарган. Америка диңгез корпусындагы һәрбер офицер аны мәҗбүри рәвештә укый.

Хәлбуки бу борынгы китап хәзер сугыш стратегиясен коручылар өчен генә ярдәмлек булудан туктады. Күп санлы бизнесменнар һәм ширкәтләр дә «Сугыш сәнгате»нең хикмәтләрен төшенде һәм үз файдасы өчен кулланды. Күп кенә япон компанияләрендә җитәкчеләргә бу китапны укып чыгу мәҗбүри. Көнбатышта да бу китап популяр: андагы идарә алымнарын Аурупа һәм АКШ эшмәкәрләре кулланырга тырыша.

2017 елда «Яңа нәшрият» үзенең эшен шундый данлыклы хезмәтне татарчага тәрҗемә итүдән башлады. Борынгы Кытай трактатының татарчага тәрҗемәсен әзерләгәндә британ синологы Лайонел Джайлсның 1910 елда дөнья күргән инглизчәгә тәрҗемәсе, рус академигы Николай Конрадның 1950 елда бастырылган русчага тәрҗемәсе һәм Чжан Цзюйшу белән Юрий Кулишенко төзегән хәзерге рус басмасы кулланылды.

1 НЧЕ БҮЛЕК. СУГЫШ АЛДЫННАН ХИСАПЛАУЛАР

Нәрсә ул сугыш

1. Сунь-цзы әйтте: сугыш — дәүләт өчен бөек бер гамәлдер. Ул яшәү белән үлемнең нигезе, йә тереклеккә, йә һәлакәткә илтә торган юл. Димәк, аны җентекләп өйрәнергә моның төбенә төшеп аңларга кирәк. Сугышны игътибарсыз калдырырга ярамый.

Биш көч

2. Шуңа күрә аның нигезенә биш күренешне (көчне) куялар [аны җиде хисап белән хисаплыйлар һәм шуның белән халәтен беләләр]. Сугышка ни кирәк дип баш ватсаң, шуларны исәпкә ал.
3. Беренче күренеш — Юл (Дао, Әхлак кануны), икенчесе — Күк, өченчесе — Җир, дүртенчесе — Сәргаскәр, бишенчесе — Канун (Кагыйдә вә ысуллар).

Юл — халыкның фикере хакимлек итүченең фикере белән тәңгәл килгәндә, халык аның белән бергә үләргә һәм аның белән бергә яшәргә әзер булганда, ул курку белән шикне белмәгәндә, бу Юл [Дао, Әхлак кануны] була.

Күк — ул яктылык вә караңгылык, салкынлык һәм эсселек, бу — вакыт тәртибе.

Җир — бу ерак һәм якын; тигезсез һәм тигез, имин һәм куркыныч; киң һәм тар юллар; бу үлем белән яшәү, исән калу һәм вафат булу мөмкинлеге.

Сәргаскәр — бу биш игелек: акыл, гаделлек (ихласлык), кешелеклек, батырлык, кырыслык.

Борынгы кытайлар фикеренчә, биш төп игелек (күркәм сыйфат) булган: 1) яхшылыклар кылу — кешелеклек; 2) акыл намуслыгы; 3) үзеңә хөрмәт, ягъни үзеңне тәртиптә тоту; 4) хикмәтлелек; 5) ихласлык (тугрылык). Безнең очракта исә хәрбиләр өчен әһәмиятле булган «батырлык» һәм «кырыслык» «акыл намуслыгы» һәм «үзеңә хөрмәтне» алыштыра.

Канун — хәрби төзелеш тәртибе, гаскәрне дөрес итеп алып бару, вазыйфаларга кешеләрне билгеләү; әмерләр бирү һәм гаскәрне тәэмин итү.

Бу биш күренеш — көч — турында ишетмәгән бер гаскәри дә юк, ләкин аларны төшенгәннәре генә сугышта җиңә; ә үзләштерә алмаганнары исә җиңми. *[Бу биш күренеш турында һәр гаскәри белергә тиеш, аларны белүчеләр җиңә, үзләштерә алмаганнар җиңелә]*

Җиде хисап

4. Шуңа күрә сугышны җиде хисап белән үлчиләр һәм шул рәвешле хәлнең нинди булуын билгелиләр. Шуңа күрә, сугышны уңышлы алып барырга теләсәң, бу хисаплар белән чагыштырып фикер йөрт.

1) Кайсы илбашы Юлдан бара (Әхлак кануныңа, Даога иярә)?

2) Кайсы сәргаскәр сәләтлерәк?

3) Кем Җир белән Күк биргән өстенлекләрне куллана?

4) Кемнең кагыйдәләрен һәм әмерләрен яхшырак үтиләр?

Гаскәр башлыклары да үзләре урнаштырган кагыйдәләргә буйсынырга тиеш. Ду Му дигән язучы Цао Цао исемлеге кытай сәргаскәре турында кызыклы риваять калдырган. Цао Цао тәртип яраткан һәм кырыс кеше булган. Үзенең аты бөртек үскән басуны таптагач, ул, ашлыкны һәртөрле зыяннан сакларга дигән әмеренә буйсынып, үзен үлем җәзасына хөкем иткән. Соңрак ул үлем җәзасы урынына чәчләрен кистереп, гаделлекне шул рәвешле кайтаруга ризалаша. «Кагыйдә урнаштырсаң, кара аны, ул бозылмасын; канун бозылса, җинаятьче җәзалансын».

5) Кемнең гаскәре көчлерәк?

6) Кемнең түрәләре һәм сугышчылары яхшырак әзерләнгән?

7) Кем дөрес итеп җәзасын һәм әҗерен бирә?

Менә шуларга карап мин кемнең җиңәсен һәм кемнең җиңеләсен әйтә алачакмын.

Сәргаскәрне ничек сайларга

5. Әгәр дә гаскәр башлыгы минем хисапларны кулланса, ул аларны үзләштереп, һичшиксез, җиңүгә ирешәчәк; мин аның янында калачакмын. Әгәр дә гаскәр башлыгы, хисапларыма төшенмәсә, һәм

аларны кулланмаса, ул һичшиксез җиңеләчәк; мин аннан китәчәкмен. Әгәр дә ул аларны мөмкин булган файданы исәпкә алып үзләштерсә, алар аңа үзләреннән тыш та булышачак куәтне тәшкил итәрләр [Башка яхшы киңәш һәм уңай форсатларга ачык булса].

6. Куәт — ул файдага туры китереп, тактиканы дөрес куллана белү. Шуңа күрә, шартлар уңайлы булганда, планнарыңны шул шартларга яраклаштыр, кагыйдәгә сукырларча иярмә.

Сугышта ялганлау

7. Сугыш — ул ялган юлы.

Шуңа күрә, әгәр нәрсә дә булса кулыңнан килсә, дошманыңа кулыңнан килмәгән итеп күрсәт; әгәр нәрсә дә булса куллансаң, кулланмаган сыман бул; якын торсаң да, үзеңне еракта итеп күрсәт; еракта булсаң да, якында булып күрен.

Уңайлы форсат күрсәтеп, дошманыңны алда; аның гаскәрен бута һәм аны кулыңа эләктер.

Әгәр аның гаскәрендә барысы да җитәрлек икән, аның һөҗүменә әзер тор; әгәр ул көчле булса, аның кулына эләкмә кач.

Дошманың сабырсыз булса, аны ярсытып, гаскәрен бута; юашлык күрсәтеп, анда мин-минлек уят.

Әгәр аның яңа гаскәрләре килгән булса, аны арыт; әгәр гаскәре дус булса, дошманлык уят; ул әзер булмаганда һөҗүм ит; ул көтмәгәндә сугышка чык.

8. Боларның барысы да юлбашчыга җиңү бүләк итәр; ләкин алдан берни дә әйтеп булмый, фаразлар белән ашыгырга кирәкми. Бу алымнар турында алдан сөйләргә ярамый.

Сугышта җиңә торган сәргаскәр сугыш башланганчы күп итеп уйлана.

Сугышка керешкәнче җиңү

9. Кем — әле сугышка кадәр үк — алдан исәп-хисаплары белән җиңә, шуңа ышаныч зур; кем — сугышка кадәр үк — исәп-хисаплары белән җиңми, аңа ышаныч азрак. Кемнең форсаты бар — шул җиңә, кемнең форсаты юк — җиңми. Шуңа күрә мин, боларны күрү белән, җиңү белән җиңелүне аңлыйм.

2 НЧЕ БҮЛЕК. СУГЫШ АЛЫП БАРУ

Гаскәрне ничек тупларга

1. Сунь-цзы әйтте: сугыш алып баруның тәртибе менә шундый:
2. Әгәр синең бер мең җиңел сугыш арбасы һәм бер мең авыр сугыш арбасы, йөз мең сугышчың булса, мең ли ара узар өчен җитәрлек кирәк-яраклар таләп ителсә, ул очракта эчке һәм тышкы чыгымнарың, кунаклар кабул итү өчен китәчәк чыгымнарың, лак һәм җилем өчен материал, сугыш арбалары һәм кораллар өчен кирәк-яраклар — болар өчен көненә мең алтын тәңкә китәчәк. Шул очракта гына йөз меңлек гаскәргә хәлең җитәр.

Әкренлекнең зыяны

3. Әгәр сугышта җиңүгә юл озакка сузылса, корал үтмәсләнә һәм кыршыла; әгәр кальганы озак вакыт камап торсалар, көчең бетә; әгәр гаскәрне кырда озак тотсалар, дәүләтнең акчасы җитми башлый.
4. Корал үтмәсләнсә һәм кыршылса, көч бетсә һәм акча җитмәсә, морзалар, синең зәгыйфьлегеңне аңлап, сиңа каршы чыгарлар. Шул чакта сиңа иң гакыллы кеше дә алда көткән бәладән котылырга булыша алмас.
5. Шуңа күрә дә сугышта уңышның көрәш тиз барганда гына килүен беләләр, хәтта сугыш дөрес алып барылмаса да, тиз көрәш җиңү бирә; ә инде дөрес алып барылып та, озакка сузылган сугышның уңышлы булуын әле күргәннәре юк.
6. Беркайчан да озын сугышның дәүләткә файда китергәне юк. Сугышның зыянын аңлап бетермәгән кеше аны отышлы итеп алып баруны бөтенләй белми.

Көчеңне дөрес куллану

7. Сугыша белгән кеше сугышчыларны ике тапкыр җыймый, азык-төлекне өч тапкыр төями; сугыш кирәк-яракларын үз дәүләтеннән ала, азык-төлекне исә дошманыннан ала. Шуңа күрә аның сугышчыларына ризыгы җитә.

Сугыш башлангач, ярдәм көтеп яки азык-төлек артыннан китеп, вакытны исраф итәргә ярамый, кичекмәстән хәрби хәрәкәтләргә тотынырга кирәк.

8. Дәүләтнең малы җитмәгәнгә, гаскәрне еракта тотарга туры килә. Азык-төлекне еракка илтергә туры килгәч, халык бөлә.
9. Гаскәр булган җирләрдә сәүдәгәрләр бәяләрне күтәрә; алар кыйммәт бәягә сатканга, халыкның малы кими; зәгыйфь халык түлисе салымнарын авырлык белән түли.
10. Көч бетә, мал кими, үз илеңдә — йортларда бушлык; халыкның малы уннан җидегә кими; илбашының малы — сугыш арбалары ватылган, атлар арыган; көбә, ук һәм җәяләр, кече калканнар һәм аю сөңгеләре, зур калканнар һәм сөңгеләр, эш үгезләре һәм йөк арбалары — болар барысы да уннан алтыга кими.
11. Шуңа күрә акыллы сәргаскәр дошман хисабына туенырга тырыша. Дошман ризыгының бер фунты үз ризыгыңның егерме фунтына тигез; дошман саламы һәм көрпәсенең бер поты үзеңнең егерме потыңа тигез.

Сунь-цзы фикеренчә, 1 фунт ризык китергәнче, 20 фунт ашалачак.

12. Дошманны ярсу җиңә, байлыкларын комсызлык талап ала. Сугышчыларың дошманга ачулы булсын, файда эзләп, әҗер-ганимәткә өметләнсеннәр.
13. Әгәр сугыш арбалары белән сугышканда ун һәм аннан да күбрәк арбаны кулга төшерсәләр, аны беренче булып кулга төшергәннәргә бүләк итеп тарат һәм әләмнәрне үзеңнекенә алыштыр. Ул арбаларны үзеңнекеләр белән катнаштыр һәм аларда йөри башла. Әсирләрең белән яхшы мөгамәләдә бул һәм аларны кайгырт. Бу дошманны җиңү һәм үз көчеңне арттыру була да инде.
14. Сугыш җиңүне ярата, ә озакка сузылуны сөйми. Сугышта төп максатың озакка сузылган яу түгел, ә җиңү булсын.
15. Шулай итеп, сәргаскәр халык язмышының хөкемдары була, дәүләтнең иминлектә яки хәвеф-хәтәрдә буласын хәл итүче кешегә әйләнә.

3 НЧЕ БҮЛЕК. СТРАТЕГИК҆ ҺӨҖҮМ

Тулылыкка омтылу

1. Сунь-цзы әйтте: сугыш кагыйдәләренә таянсаң, иң яхшысы — дошман дәүләтен кулга төшерү һәм саклап калу, моннан икенче урында — бу дәүләтне юк итү. Иң хәерлесе — дошман гаскәрен кулга төшерү һәм саклап калу, аннан кала икенче урында — аны тар-мар итү. Шул рәвешле, дошманыңның төмәнен, меңен, йөзен һәм дистәсен кулга төшерү һәм саклап калу аны юкка чыгарудан хәерлерәк булыр.

Борынгы Кытайда гаскәр корпусында (шартлы рәвештә әйткәндә, төмән — 10 меңлек гаскәрдә) 12,5 мең кеше булган; полк, яки меңдә 500 кеше торган, рота, яки йөзгә 100—500 кеше кергән, дистә яки бүлеккә 5—100 кеше кергән. Биредә «төмән», «мең» кебек төшенчәләр төрки-татар хәрби традициясе нигезендә кулланыла.

Йөз тапкыр сугышып, йөз тапкыр җиңү — иң хәерлесе түгел, иң яхшысы — дошман гаскәрен сугышсыз буйсындыру.

Һөҗүмнең төрләре

2. Шуңа күрә иң яхшы сугыш алымы — дошманыңның планнарына юл куймау; аннан соң яхшы булганы — аның берләшмәләрен, дуслары белән берлекләрен тар-мар итү; тәртип буенча, аннан соң яхшысы — дошман гаскәрләрен сугыш кырында җиңү, ә иң начары — кальгаларны камалышта тоту.

Камалыш кагыйдәләре кушуынча, бу адымнарга этәргән сәбәпләр җитди булырга тиеш. Пәрдәләрне, күчмә сыену урыннарын һәм башка сугыш кирәк-яракларын һәм җайланмаларын әзерләү, ясалма калкулыклар өю өчен өч ай кирәк.

«Пәрдәләр» дип 3 әйбер аталган булырга мөмкин: штурм вакытында сугышчыларның башын каплар өчен кулланыла торган зур

калканнар; тәгәрмәчле арбалар; шәһәр диварларының манаралары. Беренче билгеләмә хакыйкатькә якынрак кебек.

Сабырсыз сәргаскәр, түземлеген җуеп, мыжгып торган кырмыскалар сыман сугышчыларын кальганы алырга дип җибәрә; әмма офицер һәм сугышчыларның өчтән бере һәлак була, ә кальга алынмый кала. Камалышның һәлакәтле нәтиҗәләре менә шундый.

Сәргаскәрнең максатлары

3. Шуңа күрә, сугыша белгән кеше бәрелешләрсез генә дошман гаскәрен буйсындырсын; дошман кальгаларын камалышта тотмыйча гына алсын; гаскәрен озак тотмыйча гына чит дәүләтне тар-мар итсен. Ул, һичшиксез, барын да тулы килеш саклап калыр һәм шуның белән Күк астында хакимлеккә дәгъва кылыр. Шуңа да бит инде коралларыңны үтмәсләндермичә дә табыш алып була: бу стратегик һөҗүм кагыйдәсе.

Сан нигезендә һөҗүм алымнары

4. Сугыш кагыйдәсе болай ди: әгәр синең гаскәрең дошманыңныкыннан ун тапкыр күбрәк икән, аны һәр яклап камап ал; көчләрең биш тапкыр күбрәк булса, аңа һөҗүм ит; көчең ике тапкыр күбрәк булса, аны өлешләргә бүл.

Гаскәрләрегез тигез көчкә ия булса, аның белән сугышырга дәртең җитсен. Көчең азрак булса, саклана бел; гомумән, нәрсәң дә булса дошманыңнан начаррак икән, аннан читкә тайпыла бел.

Аз көч белән сугышырга омтылучылар көчле дошманның әсирләренә әйләнә.

«Һөҗүм итүче һәм саклаучы гаскәрләрнең көче тигез булса, сәләтле сәргаскәр генә сугышка керә ала», дип әйтелә төрле шәрехләрдә.

Илбашының гаскәргә йогынтысы

5. Сәргаскәр — дәүләтнең терәге. Әгәр терәк нык тора икән, дәүләт көчле булыр; терәкнең зәгыйфь яклары булса, дәүләт тә зәгыйфь булыр.

6. Илбашы өч очракта гаскәргә зыян сала:

1) Гаскәрнең кузгалырга тиеш булмаганын белмичә, аңа кузгалырга әмер бирсә; чигенергә ярамаганын белмичә, чигенергә кушса; бу гаскәрне кешәнләгән сыман була.

«Затлы атның аягын бәйләп куйган сыман була», дигән шәрехләр бар.

2) Гаскәрнең ни икәнен аңламыйча, аның белән дәүләттә идарә иткән төсле идарә итмәкче булса; бу очракта хәрби җитәкчеләр аптырашта калачаклар.

3) Тактиканың ни икәнен белмичә, сәргаскәрне дәүләт хезмәтчеләрен билгеләгән төсле билгеләсә; бу вакытта хәрби җитәкчеләрнең ышанычы кими.

7. Гаскәр аптырашта калып, сәргаскәргә ышанмый башласа, морзалардан бәла көт. Үз гаскәреңне таркатып, җиңүне дошманыңа бирү шушы була инде.

Җиңүне фараз кылу

8. Шуңа күрә биш очракта җиңүнең булачагын тәгаен беләләр:

1) Кайчан сугышырга яраганын, ә кайчан ярамаганын белсәләр, җиңәләр;

2) Зур көчне дә, аз көчне дә дөрес файдалана белсәләр, җиңәләр;

3) Өстәгеләр дә, астагылар да, бер теләк һәм уй белән йөрсәләр, җиңәләр;

4) Үзләре сак булып, дошманның саксызлыгын көтсәләр, җиңәләр;

5) Сәргаскәр сәләтле булса, һәм илбашы аңа әмерләр бирмәсә, җиңәләр.

Бу биш нигез җиңүне белү юлы була.

«Илбашының эше — гомуми нәсыйхәтләр бирү, әмма сугыш барышында карарлар кылу һәм боерык бирү — сәргаскәрнең вазыйфасы», дип шәрехлиләр.

Дошманны белү

9. Шуңа күрә әйтәләр дә инде: әгәр дошманыңны һәм үзеңне белсәң, йөз тапкыр сугышып та, иминлектә булырсың; үзеңне белеп, бу юл белән таныш булмасаң, бер тапкыр җиңәрсең, ә икенчесендә җиңелерсең; юлны да, үзеңне дә белмәсәң, сугыш кырына чыккан саен җиңеләчәксең.

4 НЧЕ БҮЛЕК. ХӘРБИ ТӘРТИП

Җиңелмәс булу

1. Сунь-цзы әйтте: элекке чорларда яхшы сугыша дип саналган кеше иң башта үзен көчәйткән, һәм шул хәлдә дошманны җиңәргә кулай вакытны көткән.

Җиңелмәслек булу үзеңнән, ә җиңә алу дошманыңнан. Тар-мар ителүдән саклану синең кулыңда, ләкин дошманны тар-мар итү мөмкинлеген дошманың бирә.

Шуңа күрә яхшы сугышчы үзен җиңәлмәслеккә әйләндерә ала, әмма ул дошманын җиңел бирелә торган итә алмый.

Шуңа да болай диләр: «Ничек җиңәргә кирәклеген белеп булса да, җиңәр өчен кирәклене эшләми калу куркынычы бар».

Кайчан һөҗүм итәргә һәм кайчан сакланырга

2. Җиңелмәс булу — саклану тактикасы; җиңә алу исә һөҗүм тактикасын кулланудыр.

Әгәр сакланалар икән, димәк, нидер җитеп бетми; һөҗүм итсәләр, димәк, барысы да артыгы белән бар.

Яхшы саклана белүче сәргаскәр тугыз кат җир астында качыр; яхшы һөҗүм итүче исә күкләр биеклегеннән дошман өстенә ябырылыр.

Шулай үзен саклый да алыр, тулы җиңүгә дә ирешелер.

Чын стратег

3. Җиңүне башка кешеләр белән бер үк вакытта күреп алган кеше осталардан оста түгел.

Әгәр кем дә булса сугышып, җиңү яуласа һәм Күк асты илендә «Шәп!» дисәләр, бу да осталардан оста сәргаскәр турында булмас.

4. Җиңел каурыйны күтәрә алу зур көч иясе булуны аңлатмый; ай белән күкне күрә алу үткен күзле булу дигән сүз түгел; күк күкрәгәнен ишетү сизгер колаклы булу түгел.

Борынгылар «яхшы сәргаскәр» дип атаган кешеләр җиңел җиңү белән җиңгәннәр. Шуңа күрә, яхшы сәргаскәр җиңгәндә, аның гакыл иясе шөһрәте дә, кыю егет даны да булмаган.

Мондый яхшы сәргаскәрләр халык ишетми-күрми торган хәлләр аркылы җиңел җиңүгә ирешәләр, шуңа күрә аларның даны ерак таралмый.

5. Шуңа күрә, ул сугышып җиңгән чакта, аның җиңүе әүвәл ясалган хисапларына туры килгән булып чыга. Хисапларына туры килгән икән, димәк, алдан башкарган барлык эшләре һичшиксез җиңүгә илткән; ул әүвәл хисаплар ярдәмендә җиңелгән дошманны җиңгән.
6. Шуңа күрә, яхшы сәргаскәр җиңелмәслек булу туфрагында басып тора һәм дошманының җиңелү форсатын кулдан ычкындырмый. Шуңа күрә дә җиңәргә тиешле гаскәр әүвәл җиңә, ә аннары яуга чыга; җиңеләчәк гаскәр исә әүвәл сугыша, ә аннары җиңү эзли.

Сугышны яхшы алып баручы зат Даога, әхлак кануннарына иярә һәм Канунны үти, тәртип саклый. Шуңа да ул җиңү һәм җиңелү белән идарә итә ала; уңыш аның кулында була.

Бәяләүләр

8. «Сугыш кануннары» нигезендә, иң әүвәл — озынлык (үлчәүләр), икенчесе — күләм (саннарны аңлау), өченчесе — сан (хисаплаулар), дүртенчесе — авырлык (мөмкинлекләрне чагыштыру), бишенче — җиңү.

Урын-җирдә үлчәүләр башкару башлана; үлчәүләрдән саннар аңлау барлыкка килә; саннарны аңлаудан хисаплаулар башлана; хисаплаулар авырлык һәм мөмкинлекләрне чагыштыру турында; бу исә җиңүне тәшкил итә дә инде.

Җиңелергә юл куймау турында

Шуңа күрә җиңәсе гаскәр тиеннәрне сумнар белән исәпләгән төсле була, ә җиңеләсе гаскәр сумнарны тиеннәр белән хисаплый.

9. Җиңүче гаскәрнең сугышы мең бу* биеклегеннән упкынга агып төшкән су агымы сыман була.

* *«Бу» — ераклыкны үлчәү берәмлеге. 1 бу якынча 1,66 метрга тигез.*

5 НЧЕ БҮЛЕК. КӨЧЛӘР

Һөҗүм вакытында гаскәрдә җитәкчелек итү

1. Сунь-цзы әйтте: күп кеше белән идарә итү аз кешене кул астында тотуга бәрабәр: хикмәт өлешләр һәм санда гына.
2. Зур гаскәрне сугышка алып бару кечкенә гаскәр башында торуга тиң: эш бары билгеләр һәм сигналлар урнаштыра белүдә генә.
3. Дошман белән очрашканда гаскәрне нәрсә беркайчан да җиңелмәс көчкә әйләндерә? Бу дөрес оештырылган туры һәм кыек хәрәкәтләр.

Кытай текстында «туры» хәрәкәтләр (маневрлар) чжэн, «кыек» хәрәкәтләр цзи дип аталган. Бу терминнарның мәгънәсен тулысынча аңлау һәм теләсә кайсы контекстка туры килгән тәрҗемә эквивалентын табу — бик тә катлаулы эш. Аларның мәгънәсе турында бәхәсләр гасырлар дәвамында бара. Мәсәлән, Ли Цюань болай яза: «Дошманны йөзгә-йөз кара-каршы очрату — чжэн була, кырыйдан узып китү — цзи». Башка күп төрле аңлатмалар да бар. Гомумиләштереп әйткәндә, түбәндәгечә килеп чыга: «Чжэн — дошманның игътибарын җәлеп иткән һөҗүм яки башка берәр хәрәкәт; цзи исә — дошман көтмәгән гамәл яки дошман көтмәгән урында башкарылган хәрәкәт. Дошман цзи буларак кылынырга тиешле хәрәкәтне сизеп алса, хәрәкәт шунда ук чжэнга әйләнә».

4. Гаскәр дошманны тегермән ташы йомырканы сыткан сыман тар-мар итә алсын өчен, аның көчле һәм зәгыйфь якларын, ягъни тулылык белән бушлыкны белү зарур.

Туры һәм кыек хәрәкәтләр

5. Гомумән алганда, сугышта дошманга каршы туры хәрәкәт белән каршы чыгалар һәм көрәшәләр, ә кыек хәрәкәтләр белән җиңәләр. Кыек хәрәкәтләр белән эш иткән кеше күк һәм җир сыман чиксез, Хуан-хэ вә Янцзы-цзян сыман саекмас булыр.

6. Кыек хәрәкәтләр сүнәләр дә, янә кабыналар — кояш белән ай шундыйдыр; үләләр дә янә туалар — ел фасыллары шундый була.

Музыканың тоннары бишәү генә, әмма шушы биш тоннан хасил булган моңнарны тыңлап бетереп булмый.

Кытай музыка системасының нигезендә биш төп тон ята: гун, шан, цзюэ, чжи һәм юй.

Асыл төсләр дә биш кенә (зәңгәр, сары, кызыл, ак һәм кара), әмма бу төсләрне катнаштыргач хасил булган яңа төсләрне күреп бетерә алмыйсың.

Тәмнәр дә биш кенә (ачы, борычлы, тозлы, баллы һәм әче), әмма кушылып барлыкка килгәч тәмнәрне татып бетерү мөмкин түгел.

Сугыш-бәрелештә ике генә хәрәкәт бар — дөрес бәрелеш (туры хәрәкәт) һәм маневр (кыек хәрәкәт), әмма туры белән кыек хәрәкәтләрнең үзгәрешләрен санап бетереп булмый. Туры хәрәкәт белән кыек хәрәкәт берсе-берсеннән хасил була. Бу мәңгелек әйләнешнең ахыры юк. Шулай булгач, бу алымнар санын кем сарыф итеп бетерсен ди?

Төгәллек

7. Ярсу ташкынның тизлегенә ташларны урыннан күчерергә мөмкинлек биргән нәрсә — аның көче. Ерткыч кошның тизлегенә корбанының җанын кыярга мөмкинлек биргән нәрсә — һөҗүмнең дөрес исәпләнгәнлеге. Шуңа күрә дә яхшы сугышчының көче ашкынулы, ә карары тиз.

Көч — ул җәяне тарту, һөҗүм карары— укны атып җибәрү.

Гаскәр ярдәмендә дошманны алдау

8. Барысы да буталып, тәртипләр бозылып бетсен, сугышның рәте-чираты югалсын, әмма барыбер тәртип бөтенләй таркалмас; барысы да кайнасын һәм ярсып чыксын, алгы сафлар да, арьергард та югалсын, гаскәрең барыбер җиңелмәс булып кала алыр.

Шундый шәрех бар: «Алдан билгеле бер тәртиптә оештырылып, төрле сигналлар системасын төзегән һәм тарала һәм тезелә белгән хәрби бүлекләр тәртибе бозылып беткән кыяфәт чыгара ала, ләкин чынлыкта алар тәртипләрен югалта алмас».

9. Уйдырма тәртипсезлек тәртиптән, уйдырма уркаклык батырлыктан, уйдырма зәгыйфьлек чын көчтән туа. Тәртип һәм уйдырма тәртипсезлек — ул сан; кыюлык һәм куркаклык — ул куәт (яшерен көч); көч һәм зәгыйфьлек — ул гаскәрне тезү рәвеше.

Ягъни чын тәртипне, кыюлыкны һәм көчне яшереп, дошманны алдар өчен гаскәреңне дөрес итеп бүләргә, яшерен көчкә ия булырга һәм бүлекләрне дөрес итеп тезәргә кирәк.

Хань династиясенең беренче императоры Гао Цзу турында шундый хикәят бар:

«Сөннәрне тар-мар кылырга теләгәч, ул дошманнарының хәле турында белер өчен шымчылар җибәрде. Ләкин сөннәр бу хакта белгәннәр иде инде, шуңа алар иң көчле сугышчыларын һәм сәламәт атларын яшерделәр, шымчылар күрсен өчен зәгыйфь сугышчы һәм хәлсез атларны гына калдырдылар. Шымчылар моны күрделәр дә, императорга яу чыгарга киңәш иттеләр. Бары Лоу Цзин гына аларга каршы чыкты. Ул болай диде: «Ике дәүләт сугышырга җыенса, алар, табигый ки, көчләре турында ялган фикер тудырырга тырышалар. Шымчыларыбыз хәлсез сугышчы һәм карт-корыдан башканы күрмәгәннәр. Шигем юк, дошман безне алдарга тели, шулай булгач, аңа яу чабырга кирәкми». Хәлбуки император бу киңәшкә колак салмады һәм сөннәр корган тозакка эләкте».

10. Дошманын хәрәкәтләнергә мәҗбүр итә алган гаскәри аңа сугыш сафларын күрсәткәндә, дошман һичшиксез аңа иярер; дошманга берәр нәрсә бирсәң, ул аны шикләнмичә алыр; табыш-файдага өметләнеп, ул хәрәкәт итәр, һәм аны көтелмәгәнлек белән каршы алырлар.

Көч куллану

11. Шуңа күрә, яхшы сугышчы гаскәри барысын да бердәмлек көченнән эзли, аерым кешеләрдән генә таләп итми. Шуңа да ул кешеләрне сайлый һәм аларны көчләренә карап бастыра белә.
12. Кешеләрне көчләренә карап бастырган гаскәри, ташлар белән агачларны әйләндереп җибәргән кебек, үз кешеләрен сугышка дөрес кертә белер. Агач белән ташларның табигатенә күрә, тигез җирдә алар тыныч яталар; сөзәклектә алар хәрәкәткә киләләр; дүртпоч-

маклы булсалар, алар кымшанмыйлар; ә түгәрәк булсалар, әйләнә башлыйлар.

13. Шуңа күрә дә башкаларны сугышка керергә мәҗбүр итә алучының көче — биеклеге мең сажин булган таудан түгәрәк таш тәгәрәтүченең көчедер.

Төп мәгънә: сугыш барышында тиз үзгәрешләр ясау һәм кинәт хәрәкәт итү бик мөһим. Шул рәвешле аз көч белән дә зур уңышка ирешеп була.

6 НЧЫ БҮЛЕК. КӨЧЛЕ ВӘ ЗӘГЫЙФЬ УРЫННАР

Беренче булып килү отышлырак

1. Сунь-цзы әйтте: сугыш кырына алдан килеп, дошманын көтүченең көче мулдан ашкан булыр; сугыш кырына соңга калып, шунда ук сугышка керүченең хәле җитмәс.

Шуңа күрә дә акыллы сугышчы дошманы белән идарә итә һәм үзе белән идарә итәргә юл куймый.

Дошманга тәэсир итү

2. Дошманыңны үзе килерлек илтә алсаң — димәк, аны табыш белән алдалап китерәсең; дошманыңа үтеп китәргә юл бирмәү — аны зыяннан куркып туктату. Шуңа күрә көче җиткән дошманның да хәлен алып була; тукны да ачыгырга мәҗбүр итә аласың; ныклап утырганны да урыныннан күчерергә мөмкин.
3. Ул һичшиксез юнәләчәк якка юлга чык та, ул көтмәгән якка юнәл. Мең чакрым узып та, талчыкмаган сугышчы кешеләр йөрми торган урыннардан бара.

Хәрәкәтләнү, һөҗүм итү вә саклану

4. Һөҗүм итеп, ышаныч белән кулга төшерү — димәк, ул сакламаган урынга һөҗүм итү; саклау һәм ышаныч белән үзеңдә калдыру — димәк, ул һөҗүм итә алмаган урынны саклау. Димәк, дошманы кайсы җирен сакларга белмәгән сәргаскәр һөҗүмдә оста саналыр; дошманы кайда һөҗүм итәргә белмәгән сәргаскәр саклануда оста булыр. Искиткеч нечкә сәнгать! Нечкә сәнгать бу — аны сурәтләр өчен бер рәвеш тә юк. Илаһи сәнгать! Илаһи сәнгать бу — аны тасвирлар өчен сүзләр дә юк. Шуңа күрә ул дошманының язмышын хәл итәчәк тә инде.

5. Дошманыңның бушлыкларына, ягъни зәгыйфь якларына юнәлеп һөҗүм итсәң, синә бер куркыныч та янамас; әгәр дошманыңнан тизрәк булсаң, артка чигенгәндә дә эзәрлекләүдән курыкмассың.

Дошманны сугышырга мәҗбүр итү һәм сугыштан котылып калу

6. Шуңа күрә, әгәр дә минем сугышасы килсә, дошманым, биек диварлар корып, тирән чокырлар казыса да, барыбер минем белән сугышмыйча калмас. Ни өчен? Чөнки мин ул һичшиксез коткарырга тиеш булган урынга һөҗүм итәм. Әгәр дә минем сугышасы килмәсә, мин бер урынга утырып, аны саклый гына башласам да, дошманым барыбер минем белән сугыша алмаячак. Ни өчен? Чөнки мин аны ул барган юлдан читкә тайпылырга мәҗбүр итәм.

Яшеренү

7. Шуңа күрә, әгәр мин дошманга үземдә чынлыкта булмаган берәр төрле тәртипне күрсәтсәм, мин бербөтен булып калырмын, ә дошман өлешләргә бүленер. Бөтенлегемне саклап, мин берлек булырмын; өлешләргә бүленгәч, дошманым дистәгә әйләнер. Шунда мин үземнең дистәм белән аның берлегенә һөҗүм итәрмен. Шулчакта без күп, ә дошман аз булыр. Менә шулай күпсанлы көч белән аз санлы гаскәргә һөҗүм итеп, дошманны аяныч хәлдә калдыра алырбыз.
8. Дошманың кайда сугыш булачагын белмәсен. Шуны белмәсә, аңа гел әзер торырга кирәк булган урыннар күп булачак. Әгәр андый урыннар күп икән, минем белән сугышачак кешеләр аз булачак. Шуңа күрә, аның алгы сафы әзер булса, артта көчләре җитмәс; әгәр арткы сафлар әзер торса, алдагы көчләр зәгыйфь булыр; сулда әзер булса, уңда хәле җитмәс; уңда әзер булса, сулда әзер булмаслар. Гел әзер тору таләп ителмәгән урыннары булмаган дошманның көчләре һәрчак җитеп бетмәс. Һәрдаим әзер торырга тиешленең көче аз; дошманын гел әзер торырга мәҗбүр итүченең исә көче җитәрлек.

Сан ягыннан өстенлек

9. Шуңа күрә, әгәр сугышның көнен һәм урынын белсәң, мең чакрымга да һөҗүмгә бара аласың. Әгәр инде сугышның урынын да, көнен дә белмәсәң, сул ягың белән уңны, уң ягың белән сулны саклый алмассың, алгы сафлар артны, арткы сафлар алны саклый алмас. Аралар ерак — берничә дистә чакрым — булса да, якын — берничә чакрым — булса да, шулай бу.
10. Мин шулай дисәм дә, менә Юэларның гаскәрләре зур, ди, әмма бу аларга җиңәр өчен нәрсә бирә соң? Шуңа күрә болай диләр инде: «җиңүне ясап була». Дошманның гаскәре зур булса-булсын, аңа сугышка керергә юл куймаска да була бит.
11. Шуңа күрә, дошманыңа бәя биргәндә, барча өстенлекләре һәм хаталары белән бергә аның планын беләләр; дошманга тәэсир итеп карап, аның хәрәкәте һәм ял итүе белән идарә итә торган кануннарны беләләр; теге яки бу хәрби тәртипне күрсәтеп, аның гомер иткән һәм үлем кичергән урынын беләләр; аның белән очрашкач, җитешсезлекләрен һәм өстенлекләрен беләләр.

Сыгылмалы булу

12. Гаскәреңнең хәрби тәртибен дөрес урнаштыруның иң камил рәвеше — тәртипнең бөтенләй күренмәве. Бу тәртип булмаса, иң эчкә кергән шымчы да берни күрмәс, хикмәт иясе дә берни аңламас. Хәрби тәртипне кулланып, ул җиңү эшен күплеккә тапшыра, әмма күплек моны белә алмый бит. Барлык кешеләр дә миңа җиңәргә булышкан хәрби тәртипне белә, әмма җиңүне оештырган тәртипне (стратегияне) беркем белми. Шуңа да сугышта җиңү шул ук рәвештә була алмый, ул хәрби тәртипнең саекмаслыгына тәңгәл килә.

Бер тапкыр җиңәргә булышкан тактиканы икенче тапкыр кулланма, синең алымнарыңны һәрдаим алмашынып торучы урын-хәл билгеләсен.

13. Хәрби тәртип су сыман: суның тәртибе — биеклектән качу һәм гел аска омтылу; гаскәрнең хәрби тәртибе — тулылыктан (көчле урыннан) качу һәм бушлыкка (зәгыйфь урынга) бәрү. Су урынга карап агымын җайлый; гаскәр, дошманына карап, җиңүен хәл итә.

14. Шуңа күрә, суның үзгәрмәс тәртибе булмаган кебек, гаскәрнең дә бертөрле хәрби тәртибе булмый. Дошманына бәйле рәвештә үзгәрешләр һәм әверелешләргә хуҗа булып, җиңүгә ирешә белүчене Күктә туган сәргаскәр дип атыйлар.
15. Шуңа күрә дә биш стихиянең (су, ут, агач, металл, җир) берсе дә гел җиңеп тормый; ел фасыллары да берсен берсе алыштырып тора. Көннәрнең кыскасы һәм озыны була, ай да бер үсә һәм бер кими.

7 НЧЕ БҮЛЕК. СУГЫШТАГЫ КӨРӘШ (МАНЕВРЛАР)

Маневрларның авырлыгы

1. Сунь-цзы әйтте: сугышны алып бару кагыйдәләре менә шушыдыр: илбашының әмерен ишеткән сәргаскәр гаскәр төзи һәм көчләрен туплый, һәм, дошманы белән элемтәгә кереп, урынына баса. Сугыштагы көрәштән дә авыррак нәрсә юк.
2. Сугыштагы көрәшнең авыр өлеше — урап уза торган юлны туры юлга әйләндерү, һәлакәттән табыш ала белү. Мондый урау юллардан хәрәкәт итеп, дошманын табыш белән кызыксындырган һәм, аннан соңрак юлга чыгып, аннан иртәрәк барып җиткән сәргаскәр урап хәрәкәт итү тәртибен беләдер.

Маневр һәм хәрби кирәк-яраклар

3. Шуңа күрә сугыштагы көрәш табыш-файдага да, куркынычка да китерә ала. Әгәр бөтен гаскәреңне күтәреп, табыш өчен көрәшсәң, максатыңа ирешә алмассың; гаскәрне ташлап калдырып, табыш өчен көрәшкә чыксаң, мал-мөлкәтеңне югалтырсың.
4. Әгәр йөз чакрымдагы табыш өчен көрәшеп, коралларны салып, көндез дә, төнлә дә ял итмичә, юлларны икеләйтеп һәм күчешләрне кушып чапсалар, өч гаскәрнең дә сәргаскәрләре әсирлеккә төшәчәк; чыдамнар алда барырлар, ә хәлсезләр артта калыр, һәм гаскәрнең уннан бере генә барып җитәр. Илле чакрымдагы табыш өчен көрәшсәләр, алгы гаскәрнең сәргаскәре авыр хәлдә калыр һәм гаскәрнең яртысы гына барып җитәр. Утыз чакрым өчен чапсалар, өчтән икесе барып җитәр.
5. Әгәр гаскәреңнең мал-мөлкәт салынган йөкләре — обозы — булмаса, ул һәлак булачак, азык-төлек булмаса, ул һәлак булачак; запаслар калмаса, ул һәлак булачак.

Сугыштагы хәрәкәт өчен нәрсә белергә кирәк

6. Шуңа күрә дә күрше морзаларның уй-фикерләрен белмәсәң, алар белән алдан шартнамәләр төземә; урын-хәлне — таулар, урманнар, кыялар, сазлык һәм упкыннарны белмәгән кешегә гаскәрне тапшырырга ярамый; җирне яхшы белгән эзтабарларга мөрәҗәгать итмәгән сугышчы урын-җирнең файдалы якларын куллана алмас.
7. Шуңа күрә дә сугышта хәйлә кулланалар; табыш-файда өчен хәрәкәтләнәләр һәм аеру вә кушулар ярдәмендә үзгәрешләр кертәләр.

Сугышта ялганла һәм уңышка ирешерсең.

8. Җилдәй җитез бул; урман сыман тыныч һәм сабыр бул; ут сыман бәреп кер һәм берни калдырмыйча тар-мар ит; тау сыман хәрәкәтсез тор; караңгылык сыман үтеп чыга алмастай нык бул; хәрәкәтләрең яшен сыман булсын.

Тизлектә җилдән, тыгыз саф белән торуда урманнан, бәреп кереп, талап чыгып китүдә уттан, урында торганда таудан үрнәк ал. Уйларың, төн кебек, караңгы булсын, хәрәкәтең яшен кебек булсын.

9. Авылларны таларга чыкканда гаскәреңә тигез өлеш чыксын; җирләрне басып алганда отышлы урыннарны бүлеп бир.
10. Барын да үлчәүгә салгач кына киләсе адымыңны атла. Туры һәм кыек алымнар тәртибен яхшы белүче җиңәчәк. Сугыштагы көрәшнең кануны шушы инде.

Сугыш хәрәкәтендә бердәмлекнең әһәмияте

11. «Гаскәр белән идарә итү» китабында әйтелгән:

Сүз белән әйтелгәнне кеше ишетмәс, шуңа да барабан һәм гонглар ясыйлар. Күз белән генә кешеләр күреп бетермәс, шуңа да әләмнәр һәм байраклар ясыйлар. Барабан белән гонглар, әләмнәр белән байраклар хәрбиләрнең колакларын һәм күзләрен бер бөтен итеп берләштерәләр. Әгәр барысы да бербөтен булса, кыю берүзе алга чыкмас, куркак берүзе артка чикмәс. Халык көтүе белән идарә итү кануны шул.

12. Шуңа күрә дә төнге сугышта күп итеп ут кабызалар һәм барабан кагалар, көндезге сугышта әләмнәр һәм байракларны күп кулланалар; шуның белән дошманның колаклары белән күзләрен алдыйлар.

Тәвәкәллек

Шуңа да гаскәрнең рухын, ә сәргаскәрнең йөрәген тартып алып була.

13. Сугышчының рухы иртәләрен күтәренке була, көндез алар сүлпәнәя, ә кичләрен өйгә кайту турында уйлый башлыйлар.

Дүрт сәнгать

Рухы күтәренке булган дошманыннан качып, күңеле төшкән яки тизрәк илгә кайту турында хыялланган дошманга һөҗүм иткән сәргаскәрне сугыша белә дип әйтәбез; бу рух белән идарә итү була инде.

14. Тәртиптә булганда, тәртипсезлекне көтәләр; тынычлыкта утырганда, дулкынлануларны көтәләр; йөрәк идарәсе шушы була инде.
15. Якын торсаң, еракташыны көт; көчең хәттин ашса, хәлсезләрне көт; тук булсаң, ачларны көт; көч белән идарә итү шушы инде.
16. Дошманыңның әләмнәре тәртиптә булса, каршы чыкма; дошманыңның ыстанына якын килеп булмаса, һөҗүм итмә; үзгәрешләр белән идарә итү шушы була.

Сугыш хәрәкәте һәм көчләрне тезү

17. Шуңа күрә сугыш алып бару кагыйдәләре менә нинди була: әгәр дошманың биектә булса, аңа туры барма; аның артында биеклек торса, аның каршысында утырма; ул юри качкан булса, артыннан кума; көче җитәрлек булса, аңа һөҗүм итмә; әгәр сине алдалап чакырса, барма; дошман гаскәре иленә кайтып китсә, аны туктатма; әгәр дошман гаскәрен камап алсаң, бер якны ачык калдыр; әгәр ул чарасыз хәлдә булса, аны артыгы белән җәфалама; сугыш кагыйдәләре шул.

8 НЧЕ БҮЛЕК. ТУГЫЗ ҮЗГӘРЕШ

Гаскәр һәм урын

1. Сунь-цзы әйтте: менә сугыш алып бару кагыйдәләре: [илбашының боерыгын ишеткән сәргаскәр гаскәрен җыя һәм көчләрен туплый].
2. Юлсыз урыннарда ыстан ясама; зур юллар чатында күрше морзалар белән шартнамәләр төземә. Ачык һәм сусыз урыннарда озак торма. Камап алынгач, тиз уйла; аянычлы хәлдә калсаң, үлгәнче сугыш.
3. Йөрергә ярамаган юллар була; һөҗүм итәргә ярамаган гаскәрләр очрый; көрәшер өчен лаек булмаган кальгалар табыла; сугышыр өчен лаек булмаган урыннар да була; илбашларының буйсынырга кирәк булмаган боерыклары да очрый.

Илбашының карарлары хәрби мәнфәгатьләрне исәпкә алсын.

Өстенлеккә омтылу

4. Шуңа күрә дә «Тугыз үзгәреш»нең өстенлекләрен аңлаган сәргаскәр сугышны ничек алып барырга кирәклеген белә.

«Тугыз үзгәреш»тә булган файданы аңламаган сәргаскәр, урынның (илнең) рәвешләрен белсә дә, аның файдасын күрә алмас.

Гаскәре белән идарә иткәндә, әгәр ул «Тугыз үзгәреш»нең сәнгатен белмәсә, «Биш өстенлек»не белеп тә, кешеләрне дөрес куллана алмас.

5. Шул сәбәпле акыллы кеше, гамәлләрен уйлап эшләгәндә, файда белән зыянны кушып эшли. Файда белән зыянны кушканда, тырышлыклар нәтиҗәгә китерә ала; зыян белән файданы кушканда, авырлык бетә ала. Шуңа күрә дошман морзаларны зыян белән буйсындыралар, эш белән хезмәт иттерәләр һәм файда-табыш белән кызыксындырып, омтылыш бирәләр.

Сәргаскәр нәрсәгә әзер булырга тиеш

6. Сугыш алып баруның кагыйдәсе шунда ки, дошман килмәс әле дип өметләнмәскә кирәк, аны нәрсә белән каршылый аласың — шуңа

таянуың зарур; ул һөҗүм итмәс әле димә, сиңа һөҗүм итү мөмкин булмасын өчен нәрсә эшләячәксең — шуңа таян.

7. Шуңа күрә сәргаскәр алдында биш куркыныч бар:

1) саксызлык: әгәр ул ничек тә булса үләргә дип омтылса, аны үтерергә мөмкиннәр;

2) куркаклык: әгәр ул ничек тә булса исән калырга тырышса, аны әсирлеккә төшерергә мөмкиннәр;

3) дуамаллык: әгәр аның ачуы тиз чыкса, аны күрәлмаслар;

4) әгәр үзен артык тәнкыйтьләсә, аны кимсетерләр;

5) әгәр кешеләрне артык сөйсә, аны тәмам йомшартырлар.

8. Бу биш куркыныч — сәргаскәрнең кимчелекләре, сугышны алып барганда алар һәлакәткә китерә ала. Гаскәрне тар-мар иткәндә, сәргаскәрне шушы биш куркыныч белән үтерәләр дә инде. Моны төшенергә кирәк.

9 НЧЫ БҮЛЕК. ЯУГА ЧЫККАН ГАСКӘР

Төрле урыннарда гаскәрне урнаштыру

1. Сунь-цзы әйтте: гаскәрләрнең урнашуы һәм дошманың артыннан күзәтүнең хикмәте менә нинди.
2. Таулар аша узганда, үзәнлекләргә таян; биектә урнаш, кояшлы якка кара. Өстә торган дошман белән сугышканда, өскә туры барма. Таулы җирдә гаскәрләрнең урнашуы шулай булыр.
3. Елганы кичкәч, елгадан ераккарак барып урнаш. Әгәр дошманың елганы кичә башласа, аны суда каршылама. Гомумән, ул ярты гаскәрен елгадан чыгаргач кына аңа һөҗүм итү отышлырак булыр; әгәр син дошманың белән сугыша башларга теләсәң, аны елга ярында ук каршылама; кояшлы якны исәпкә алып, биек урынга барып урнаш; агымга каршы урнашма. Гаскәрләрнең елга янында урнашуы турында сүз шул булды.
4. Сазлыктан чыкканда, тиз бул, озаклап торма. Әгәр инде саз арасында сугышырга туры килсә, су һәм үлән булган җирдә урнашырга тырыш, артыңда, тылда урман булсын. Гаскәрләрнең сазлыкта урнашуы турында шул.
5. Тигезлекләрдә булсаң, тип-тигез урыннарда урнашырга тырыш, әмма уң ягыңда һәм артыңда калкулыклар булсын; алда түбән, артта биек булсын. Гаскәрләрнең тигезлектә урнашуы турында шушы булды.

Гаскәр урнаштыру кагыйдәләре

6. Гаскәрләрне отышлы итеп урнаштыруның менә бу дүрт ысулы Хуан-дигә дүрт императорны җиңәргә мөмкинлек бирде.
7. Гомумән, әгәр дә гаскәр биек урыннарны яратып, түбәнлекләрне сөймәсә, кояш яктысын яратып, күләгәдән качса; тормышы турында кайгыртып, каты туфракта урнашса, гаскәрдә авырулар булмас. Димәк, һичшиксез, җиңәрсең.

8. Әгәр калкулыклар һәм биеклекләр арасында урнашасың икән, аларның кояшлы ягында тор, калкулыклар уңда һәм артта булсын. Бу гаскәрең өчен отышлы; бу — җир-урынның сиңа ярдәме.
9. Әгәр көчле яңгырлар явып, елга өсте күбекләнсә, аны кичәргә җыенган сәргаскәр елганың тынычланганын көтсен.
10. Гомумән, бу урыннарда текә ярлар, ташкын аккан тарлавыклар, табигый коелар, табигый базлар, табигый челтәрләр, тозаклар, тишекләр, ат белән арбалар узалмаслык сазлыклар, ук атып булмаслык куе куаклык вә үләнлекләр һәм су тулы тирән упкыннар булса, ул җирләрдән китәргә ашык һәм анда башка якын килмә. Әмма үзең аннан китсәң дә, дошманыңны шунда барырга мәҗбүр ит. Аның белән очрашкач, мондый урыннарны аның тылында калдыр.
11. Гаскәрең хәрәкәт иткән җирдә чокырлар, упкыннар, куаклыклар, урманнар һәм агачлыклар булса, аларны игътибар белән тикшер. Мондый урыннарда дошман сак куярга һәм һөҗүм итәр өчен яшерен нокталар оештырырга ярата.

Дошманның нишләгәнен белү

12. Әгәр дә дошманым, миңа якын булып та, бер дә борчылмый икән, димәк, ул табигый бер киртәгә ышана.

Әгәр дошманым миннән ерак булып та, мине сугышка дәшсә, димәк, ул алга атлавымны, урын алыштыруымны тели. Әгәр дошман тигез урында утырган икән, димәк, аның үз өстенлекләре бар (аны камау җиңел булып күренсә, димәк, ул хәйлә корган).

13. Агачлар селкенә башласа, димәк, ул якынлаша. Үләннәрдән киртәләр корылган булса, ул сине алдарга тели.

Әгәр кошлар ояларыннан очып чыкса, димәк, анда сине көтеп утыралар. Әгәр җәнлекләр курыкса, димәк, анда кемдер качкан.

Тузан багана булып күтәрелсә, димәк, сугыш арбалары килә; әгәр тузан киң урында түбән булып җәелсә, димәк, җәяүле гаскәр атлый; әгәр дә ул төрле урыннардан күтәрелсә, димәк, дошманың ягулык җыя. Әгәр ул бер монда, бер тегендә һәм аз-аз булып күтәрелсә, димәк, ыстан коралар.

14. Дошманың юаш сөйләшеп тә, әзерлеген көчәйтсә, ул юлга чыгарга җыена. Тәкәббер сөйләшеп, алга ашыкса, димәк, артка чигенә.

Тарихчы Чжан Ю «Ши Цзи» китабында (б.ч.к. 109—91 еллар) Ци ханлыгының сәргаскәре Тянь Дань Янь ханлыгыннан Ци Цзе җитәкләгән гаскәргә каршы сугышуы турында яза. Анда шундый хикәят бар:

«Тянь Дань әйтте: «Мин шуннан гына куркам — яньнәр әсирлеккә төшкән сугышчыларыбызның борыннарын кисеп, аларны гаскәрләренең алгы сафында безгә каршы чыгармасыннар иде, алай итсәләр, без шәһәрне югалтырбыз». Ци Цзе бу сүзләр турында ишеткәч, нәкъ шулай эшли дә, ләкин шәһәрне яклаучылар, ватандашларының йөзләрен күргәч, ярсуга бирелгәннәр һәм, дошман кулына төшкәч, үзләрен дә шундый язмыш көтәчәгеннән генә курыкканнар. Бу аларга көч биргән һәм ныграк сугышырга мәҗбүр иткән. Шуннан соң Тянь Дань үзенең ягына аударган Ци Цзе шымчыларын җыйган да, болай дигән: «Мин шуннан гына куркам — Янь сугышчылары шәһәр артындагы зиратта бабаларыбызның каберләрен мәсхәрә итә күрмәсеннәр иде, алай эшләсәләр, гаскәребезнең рухы төшәр». Шәһәрне камаучы яньнәр шунда ук каберлекләрне актарып чыкканнар һәм андагы сөякләрне яндырганнар. Циләр мондый вәхшәтне күреп елаганнар һәм шуннан соң аларның сугышка чыгарга дәртләре арткан, ярсулары көчәйгән. Тянь Дань аларның теләсә нинди каһарманлыкка әзер булуларын белгән. Әмма ул кулына кәтмән алган һәм иң оста сугышчыларына кәтмән тоттырган, хатыннар, картлар һәм авыруларны алар урынына бастырган. Шуннан соң ул барлык азык-төлекне таратып бетерергә әмер биргән һәм кешеләрен туйганчы ашаткан. Чын сугышчылары на яшеренергә кушкан, шәһәр диварларына картлар, хатыннар һәм авыруларны җибәргән. Моны эшләгәннән соң, ул шәһәрнең бирелүен хәл итәр өчен дошман ыстанына илчеләр җибәргән. Янь сугышчылары шатлыктан кычкыра башлаган. Тянь Дань 20 мең лян (якынча 756 кг) көмеш тә җыйган һәм шәһәр байларына аны Ци Цзега илтеп, йортларын талаудан, хатыннарын хурлыктан сакларга дип ялварырга кушкан. Ци Цзе, сөенеп, вәгъдә бирә; аның гаскәре исә тәмам йомшара һәм ваемсызга әйләнә. Менә шуннан соң Тянь Дянь бер мең үгез туплый, аларны кызыл ефәк белән бизи, тәннәрен аждаһа төсләренә буйый, мөгезләренә очлы пычаклар, ә койрыкларына майланган камыш сабакларын бәйләтә. Төн җитүгә ул сабак очларына ут төртә һәм шәһәр диварларындагы тишекләрдән үгезләрне чыгара, артларыннан иң оста биш мең сугышчысын да җибәрә. Авыртудан акылдан язган хайваннар дошман ыстанына бәреп кергәннәр: янган койрыкларының

уты кот очыргыч иләмсез гәүдәләрен яктырткан, мөгезләрендәге корал юлларында очраган һәркемне яралаган һәм үтергән. Авызларына чүпрәк тыгылган биш мең сугышчы исә тавыш-тынсыз гына ыстанга җитеп, дошман өстенә ябырылганнар. Шул ук мизгелдә шәһәрдә гөрселдәгән һәм дөбердәгән тавышлар яңгырый башлаган: шәһәр диварлары эчендә калган кешеләр бар көченә шауларга тотынганнар, алар барабан да какканнар, савыт-сабаны да шакылдатканнар. Җир һәм күк дер калтыраган төсле булган. Куркып беткән яньнәр кайсы кая качкан, ә циләр аларны эзәрлекләгән, сәргаскәр Ци Цзены исә алар үтерә дә алганнар. Менә шулай Ци дәүләте җитмеш шәһәрен кире кайтара алды».

Җиңел сугыш арбалары алга чыкса, ә гаскәр үзе аларның кырларында урнашса, димәк, дошман хәрби тәртипкә тезелә.

Әгәр дә ул, көче бар килеш тә, солых сорый икән, аның яшерен фикерләре бар.

Әгәр дә хәрбиләре чабыша башласа һәм арбаларны тезәргә тотынса, сәгать суккан дигән сүз. Әгәр ул бер алга барып, бер чигенсә, димәк, ул сине хәйләләмәкче була. Хәрбиләр сөңгеләренә таянып басып торсалар, алар ач дигән сүз. Әгәр алар, су алганда, аны савытка тутырганчы иң әүвәл үзләре эчә икән, димәк, сусаудан җәфаланалар.

Әгәр дошман үзенә файда-табыш күрсә, әмма алга чыкмаса, димәк, ул арыган.

Гаскәрнең хәле турында бер кешенең кыланмышыннан белеп була.

15. Кошлар көтүләре белән җыелса, анда беркем дә юктыр. Дошман ыстанында төнлә бәхәсләшсәләр, андагы кешеләр борчыла дигән сүз. Әгәр гаскәрнең тәртибе китсә, сәргаскәрнең абруе юктыр. Әләмнәр бер урыннан икенчесенә күчеп йөрсә, анда тәртипсезлек хөкем сөрә дигән сүз. Башлыклар сүгенсә, сугышчылар арыган була. Атларга бодай ашатып, үзләре ит белән туклансалар; шәраб савытларын агачларга элмәсәләр һәм кире ыстанга кайтмасалар, димәк, алар — соң чиккә җиткән юлбасарлар.
16. Сәргаскәр хәрбиләре белән йомшак кына һәм түбәнчелек белән сөйләшсә, димәк, ул гаскәрен югалткан. Исәпсез-хисапсыз бүләкләр таратса, гаскәре авыр хәлдә дигән сүз. Әгәр аны-моны уйламыйча хәрбиләрен җәзаласа, димәк, гаскәре шулай ук авыр хәлдә. Әгәр ул башта рәхимсез булып, аннары гаскәреннән курыкса, димәк, ул хәрби сәнгатьне бөтенләй аңламый.

17. Әгәр дошманың килеп, әсирләр тәкъдим итсә һәм гафу үтенсә, димәк, аңа ял кирәк. Әгәр инде гаскәр, ярсый-ярсый, каршыңа чыкса, әмма озак вакыт дәвамында сугышка да кермәсә, артка да чикмәсә, аның артыннан игътибар белән күзәт.
18. Гаскәр санын арттыруда гына түгел хикмәт. Хәрби көч белән генә алга барып булмый. Көчләреңне туплап, дошманыңа дөрес бәя бирү ысулы белән, дошманыңны җиңәр өчен җитәрлек гаскәр генә кирәк. Башын эшләтеп карамыйча, дошманына игътибарсыз булган сәргаскәр аның әсиренә әйләнер.

Тәртипнең мөһимлеге

19. Әгәр дә син үзеңә ияләшеп бетмәгән солдатларны җәзаласаң, алар сиңа буйсынмас; ә әгәр алар буйсынырга теләмәсә, аларны куллану авырбулачак. Әгәр солдатлар сиңа ияләшсә, әмма син аларны җәзалаудан баш тартсаң, аларны бөтенләй бер дә куллана алмассың.
20. Шуңа күрә, аларга әмер биргәндә, башта кешелеклелек күрсәт, әмма алар белән нәкъ хәрбиләрчә идарә ит. Бу җиңүгә ышанычлы юл булыр.
21. Әгәр кануннар, гомумән, үтәлсә, бу очракта, әгәр халыкка берәр нәрсә әйтсәң, алар сиңа буйсынырлар. Кануннар бөтенләй үтәлмәгәндә, син аларга ни әйтсәң дә, сиңа буйсынмаслар. Кануннар җиңел аңлаешлы булып, аларны ышаныч белән кабул итсәләр, син халык белән бер-берегезне тапкан буласыз.

10 НЧЫ БҮЛЕК. УРЫН-ҖИР

Урыннарның төрләре

1. Сунь-цзы әйтте: урыннарның алты төрлесе була:
1) ачык;
2) авыш (буталчык);
3) каршылык һәм киртәләр булганы (көтәргә кирәк булган урыннар);
4) үзәнлекле (тар);
5) таулы (текә);
6) ерак урыннар.
2. Мин бара алсам, ә ул килә алса, мондый урын ачык дип атала. Ачык урында беренче чиратта калкурак җирдә, аның кояшка караган ягында урнашырга тырыш, һәм кичекмәстән үзеңә азык-төлек китертү юлларын оештыр. Мондый шартларда сугышка чыксаң, өстенлегең булыр.
3. Баруы җиңел, ә кайтуы авыр булган урынны авыш, яки буталчык диләр. Авыш җирләрдә, әгәр дошманың сугышка әзер булмаса, аны җиңә алырсың; әгәр ул әзер булса, җиңмәссең. Артка чигенү исә авыр булачак, димәк, өстенлегең дә булмас.
4. Миңа да, аңа да йөрү уңайсыз булган урынны каршылыклы һәм киртәле (көтеп торулы) диләр. Мондый урында, дошманың отышлы бер мөмкинлек бирсә дә, сугышка кермә. Гаскәреңне җый да, кит; дошманыңны монда яртылашка гына керергә мәҗбүр ит; әгәр шул чакта аңа һөҗүм итсәң, уңарсың.
5. Үзәнлекле тар урынга беренче булып кереп утырсаң, аны тулысынча үзеңнеке ит һәм дошманны көт; әгәр ул беренче килеп, анда җәелеп урнашса, аңа иярмә. Ә инде тулысынча җәелмәгән булса, иярә аласың.
6. Таулы урынга беренче булып килеп җитсәң, өскәрәк мен һәм кояшлы якта бас, шулай итеп дошманыңны көт; әгәр дошманың алдан килеп өлгергән булса, гаскәреңне җый да, кит; дошманың артыннан иярмә.
7. Ерак урында, әгәр көчләр тигез булса, дошманны сугышка дәшү авыр, әгәр сугышны башласаң, барыбер өстенлек булмаячак.

Бу алты фикер урын-җир турында өйрәтмәне тәшкил итә. Сәргаскәрнең бөек вазифасы — боларны төшенү.

Гаскәрнең 6 бәласе

8. Табигый сәбәпләр аркасында килеп чыкмыйча, сәргаскәрнең хаталары сәбәпче булган алты бәла бар:
1) гаскәрнең ашыгып чигенүе;
2) аның буйсынмавы;
3) рухның түбән төшүе;
4) таркалуы;
5) гаскәрдә тәртипсезлекләр башлану;
6) гаскәрнең качуы (җиңелүе).
9. Шартлар бертигез булганда, үзеннән ун тапкырга зуррак гаскәр белән сугышканда, гаскәр ашыгып артка чигенәчәк.

Солдатлар көчле булып, башлыклар йомшак булса, димәк, гаскәр буйсынмый башлаячак.

Башлыклар бик көчле, ә сугышчылар зәгыйфь булса, гаскәрнең рухы түбән төшәчәк.

Әгәр дә өлкән башлыклар, җитәкчеләренә котырып, аңа буйсынмасалар, һәм, дошман белән очрашкач, җитәкчегә үч итеп сугышка керсәләр, бу сәргаскәрнең аларның сәләтләрен белмәү белән аңлатыла. Бу гаскәрдә таркаулык дигән сүз.

Сәргаскәр үзе зәгыйфь һәм юаш булганда, солдатларны әзерләүнең анык тәртипләре булмаганда, башлыклар белән гади хәрбиләрнең бер даими эшләре булмаганда, сугыш тәртибе белән тезелгәндә барысы да кыек булганда, гаскәрдә тәртипсезлек диләр.

Сәргаскәр дошманга бәя бирмәсә, зәгыйфь чагында көчлегә һөҗүм итсә, гаскәрендә сайлап алынган бүлгеләр булмаса, димәк, бу гаскәр качачак.

Бу алты фикер дошманның җиңелүе турында өйрәтмәне тәшкил итә. Чын сәргаскәр боларны аңларга тиеш.

Сәргаскәргә кирәкле сыйфатлар

10. Урын шартлары — гаскәргә ярдәм генә. Бөек сәргаскәр фәне дошманны бәяли, җиңүне оештыра, урынның төрен һәм ераклыкны

исәпли белүдән гыйбарәт. Моны белеп сугышка кергән сәргаскәр, һичшиксез, җиңәр; моны белмичә сугыша башлаган кеше җиңелмич калмас.

11. Шуңа күрә, әгәр сугыш фәне җиңәчәгеңне әйтеп торса, илбашы «Сугышма» дигәндә дә, сугыш. Әгәр сугыш фәне җиңеләчәгеңе әйтеп торса, илбашы «Сугыш» дигәндә дә, сугышма.
12. Шуңа күрә дә, сугышканда дан артыннан кумыйча, артка чигенгәндә җәзаланудан курыкмыйча, халык һәм илбашына файда турында гына уйлаган кеше — дәүләтнең хәзинәсе.
13. Хәрбиләреңә үз балаларыңа караган сыман карасаң, алар белән иң тирән тарлавыкка да керә алырсың; сугышчыларыңа кадерле балаларыңа караган төсле карасаң, алар синең белән үлемгә дә барырга әзер булырлар. Ләкин алар белән мәрхәмәтле булып, аларны дарә итә алмасаң; аларны яратсаң, әмма боерыклар бирә алмасаң; тәртипсезлек башлангач, тәртип урнаштыра алмасаң, балаларың тыңлаусыз булыр, һәм аларны яуда кулланып булмас.

Җиңү өчен шартлар

14. Хәрбиләрең белән дошманга һөҗүм итеп булганын күрсәң һәм шул ук вакытта һөҗүм итәргә ярамаганын күрмәсәң, яртылаш кына җиңәчәксең. Әгәр дә дошманга һөҗүм итәр өчен форсат барлыгын күрсәң, әмма солдатларыңның моңа әзер түгеллеген күрмәсәң, җиңүең тагын яртылаш булыр. Дошманга һөҗүм итеп булганын күрсәң, солдатларың белән һөҗүмгә барып булганын аңласаң, әмма урын шартларының һөҗүм өчен уңайсыз булуын күрмәсәң, җиңүең шулай ук яртылаш кына булыр.
15. Шуңа күрә сугышны белгән кеше юлга чыгып ялгышмас, өскә күтәрелеп, бәлагә тарымас.
16. Шуңа күрә әйтәләр дә инде: әгәр дошманыңны һәм үзеңне белсәң, җиңү якында гына; ә инде Күкне һәм Җирне дә белсәң, җиңү, һичшиксез, синеке булыр.

Өч нәрсә: кешеләрнең хәле, күк яктырткычларының урыны һәм җир-урын биргән өстенлекләр турында белсәң, сугыш җиңүең белән тәмамланыр.

11 НЧЕ БҮЛЕК. ТУГЫЗ УРЫН

Сугыш вакытында очрый торган урыннар

1. Сунь-цзы әйтте: сугыш сәнгате тугыз төрле урынның сугыш кырына әверелә алуын белә:

1) таркау урыннар;
2) ышанычсыз урыннар;
3) бәхәсле урыннар;
4) катнаш (ачык) урыннар;
5) чатта торган урыннар;
6) куркыныч урыннар;
7) юлсыз урыннар;
8) камалган урыннар;
9) үлем урыннары.

2. Морзалар үз җирләрендә көрәшсә, бу таркау урын дип атала. Алар чит җирләргә керсәләр, әмма бик эчкә бармасалар, бу урынны ышанычсыз диләр.

Мин аны басып алсам, һәм бу миңа файдалы булса, соңрак ул да аны басып алып, аңа да отышлы булып чыкса, бу бәхәсле урын булыр.

Ул да, мин дә үтеп чыга ала торган җир булса, катнаш урын дип аталыр. Өч илнең күршесе булып торган җирне яулап алган кеше Күк астына хуҗа була икән, димәк, бу урын чатта торган урын булган.

Чит җиргә бик эчкә кергәч, тылда ныгытылган кальгалар күп калса, бу куркыныч урын була. Таулар һәм урманнар, упкыннар һәм кыялар, сазлыклар арасыннан барсалар, бу юлсыз урын дип атала. Керү юлы тар, ә чыгар өчен урау юл кирәк булса, дошман аз гаскәре белән дә минем зур гаскәремә һөҗүм итә алса, бу камап алынган урын була.

Җитез генә һөҗүмгә күчеп, исән калсаң, ә җитез һөҗүм ясамасаң, һәлак буласың икән, бу урынны үлем урыны дип атыйлар.

Тугыз урынның берсенә эләксәң, нишләргә

3. Шуңа күрә таркау урында сугышма. Ышанычсыз урында туктама. Бәхәсле урынга кермә. Катнаш урында элемтәне югалтма. Чаттагы урында шартнамәләр төзе. Куркыныч урында беркемне дә талама. Юлсыз урында бар гына. Камалган урыннарда башыңны эшләт. Үлем урыннарында көрәш.

Сәргаскәрлек сәнгате

4. Әүвәлге чорларда оста итеп сугыш алып бара белгән кешеләр ничек итеп дошманның алгы һәм тылдагы сафларын үзара аралаштырмаска, зур һәм кечкенә бүлекләрне бер-берсенә ярдәм иттермәскә һәм яхшыларны начарлар белән берләштерттермәскә икәнен белгәннәр; алар дошман солдатларын аерып, яңадан бергә җыелмаслык иткәннәр, бер гаскәр итеп тупланган көчләрнең бердәмлеген тарката алганнар.
5. Дошманың зур һәм тәртипле гаскәр белән килсә, нишләрсең? Үзем җавап бирәм: беренче чиратта аңа кадерле булган нәрсәне яулап ал. Яулый алсаң, ул сиңа буйсыныр.
6. Сугышта иң мөһиме — тизлек: дошман барып җитмәгән нәрсәне яуларга кирәк; ул уйлап та карамаган юллардан йөр; ул көтмәгән яктан һөҗүм ит.

Басып алучының кагыйдәләре

7. Сугышта кунак сыман катнашасың килсә, дошман иленең эченә кергәч, барлык фикер һәм көчләреңне бер нәрсәгә генә тупла, шул чакта хуҗа сине җиңә алмас.
8. Ашлыкка бай басуларны талап, гаскәреңә җитәрлек икмәк әзерлә; кешеләрең турында кайгырт һәм аларны артык талчыктырма; аларның рухларын күтәр һәм көчләрен берләштер.

Гаскәрләрне урыннан-урынга күчергәндә, планнарың һәм хисапларыңа ярашлы рәвештә эшлә, беркем дә синең планнарыңны аңламаслык итеп фикер йөрт.

9. Сугышчыларыңны качып китү мөмкинлеге булмаган урыннарга бастыр һәм алар үлгәнче сугышырлар. Әгәр дә алар үлемгә дә барырга риза булсалар, ничек инде җиңми калырга була? Мондый вакытларда сугышчылар да, башка кешеләр дә барлык көчләрен туплыйлар. Үлем куркынычы янаган солдатлар бернәрсәдән дә курыкмый; чыгар юлы калмагач, алар бик каты торалар; дошман җиренең эченә үтеп кергәч, аларны бернәрсә туктатмый; инде берни эшли алмасалар, алар кул белән сугыша башлыйлар.
10. Шул сәбәпле сугышчылар беркем әйтмәсә дә, игътибарлы булалар, мәҗбүр итмәсәләр дә, көч вә энергия туплыйлар, үгет-нәсыйхәтсез дә үзара дус-тату булалар, боерыкларсыз да җитәкчеләренә ышаналар.
11. Әгәр теләсә нинди күрәзәләрне тыеп, һәртөрле шикне бетерсәң, сугышчыларның аңы үлем сәгате җиткәнчегә кадәр юк-бар белән мавыкмас.
12. Сугышчылар «мал-мөлкәт безгә башка кирәкми», — дисәләр дә, бу алар байлык яратмый дигән сүз түгел. «Яшәү башка кирәк түгел!» — дисәләр дә, алар тормышны яратмый дигән сүз түгел бу.

Хәрби әмер чыккан көнне, башлыклар һәм сугышчыларның утырып торганнарының яшьләре муен якаларына агып төшә, ятып торганнарның яшьләре ияк асларына ага. Әмма чыгып булмастай хәлгә җиткерелгәч, алар бюатыр Чжуань Чжу һәм Цао Куй сыман кыюга әйләнәләр.

Шуайжаньга тиң сәргаскәр

13. Шуңа күрә, сугышны яхшы алып баручы кеше Шуайжаньны хәтерләтә. Шуайжань — чаншань еланы. Башына суксалар, ул койрыгы белән тибә, койрыгына бәрсәләр, ул башы белән суга; уртасына суксалар, ул башы һәм койрыгы белән тибә.
14. Йә, сорап карыйм инде: гаскәрне дә чаньшан еланына охшатып буламы? Җавап та бирәм: әйе, була. У белән Юэ халыклары дошманнар. Әмма бергәләп елганы кичкәндә өсләренә давыл ишелсә, алар, уң кул сул кулга булышкан сыман, бер-берсен коткарырга тотыначаклар.
15. Шул сәбәпле, хәтта атларны бергә бәйләп, арбаларының тәгәрмәчләрен җиргә күмсәң дә, моның ныклыгына ышанып булмый. Ә менә сугышчыларың барысы да бергә кыю икән, гаскәр белән идарә итү сәнгате шул була инде.

16. Көчлеләр һәм зәгыйфьләрнең икесе дә кыюга әйләнсә, монда урынны куллану кануны эшли. Шуңа да оста сәргаскәр бер кешене кулыннан тотып барган сыман, гаскәрен дә җиңел генә алып барыр.

Сәргаскәр өчен кирәкле күнекмәләр

17. Менә гаскәр башының эшләре: ул үзе һәрвакыт тыныч һәм серен чишмәс кеше булсын; намуслы һәм гадел булып, тәртипне башта үзендә булдырсын.

Ул үзенә буйсынган башлыклар һәм сугышчыларның колаклары белән күзләрен алдый алырга тиеш, чөнки аларга нәрсә дә булса белергә ярамый.

Уйларын үзгәрткәндә һәм планнарын алыштырганда башкалар бу хакта сизмәсеннәр. Ул ыстанын алыштырып торырга һәм урау юлларны сайлап, башкаларның бу хакта белми калуларын тәэмин итәргә бурычлы.

18. Гаскәрне алып барганда, аны шундый шартларга куй: имеш, алар өскә менгәннәр дә, аннары баскычны алып куйганнар. Гаскәрең белән берәр морзаның җирләренә бик эчкә кергәч, кыю адымнарга бар: корабларны яндыр һәм казаннарны ват; солдатларны сарык көтүен куган сыман йөрт: аларны монда куалар һәм шунда баралар; тегендә куалар да, алар шунда баралар, асылда, кая барганнарын белмиләр.

Гаскәрне тулысынча җыеп бетергәч, аны куркыныч янаган җиргә ташла; гаскәр башының эше шул була инде.

19. Тугыз төрле урынга хас булган гамәлләрнең күптөрлелеге, һөҗүм итү һәм саклану тактикаларының отышлы һәм отышсыз булуы, кеше табигате һәм хисләре буйсынган кануннар — боларның барысын да өйрәнергә һәм аңларга кирәк.

Дошман җирендә нишләргә

20. Гомумән алганда, сугыш сәнгатендә кунак рәвешендә сугышканда болай эшләргә кирәк диелә: әгәр дошман җиренә тирәнгә керәсең икән, игътибарыңны бер нәрсәдә туплаячаксың; әгәр бик тирән кермәсәң, фикерең чуалачак.

Үз илеңнән чыгып, чит җирләрдә сугышканда, ул урынны аерымланган урын дип атыйлар. Юллар һәр якка да ачык булса, бу чаттагы урын була.

Әгәр бик тирән керсәң, куркыныч урынга тап буласың; әчкә бик кермәсәң, ышанычсыз урында каласың; артта үтеп булмаслык җирләр калса, ә алда — тар кысанлыклар көтсә, бу камалган урын булыр; ә инде барыр һәм чигенер урын калмаса, бу үлем урыны дип аталыр.

21. Шуңа күрә дә мин таркау урында һәркемнең омтылышларын бер якка юнәлтәчәкмен. Ышанычсыз урында бүлекләр арасында элемтәне саклаячакмын. Бәхәсле урынга дошманымнан соң гына барачакмын; катнаш урында саклануга игътибар итәрмен; чаттагы урында дуслар белән элемтәләрне ныгытырмын. Куркыныч урында азык-төлек килсен өчен даими юл оештырырмын; юлсыз урында юл буйлап әкрен генә атларбыз. Камалу урынында чыгу юлын үзем каплармын; үлем урынында исә сугышчыларны монда берәү дә исән калмаячак дип ышандырырмын. Сугышчыларның рухы шундый: әгәр аларны камап алсаң, алар саклаcalled; башка чара калмаса, сугышалар; ә инде хәл җитди булса, буйсыналар да.

Сугыш алып бару мәсләкләре

22. Күрше морзаларның башында ни булганын белмәгән кеше алар белән шартнамәләр төземәсен. Шартларны — таулар, урманнар, калкулыклар, ярлар, сазлыклар һәм упкыннарны — белмәгән кеше гаскәр башы була алмый. Җирле эзтабарларга мөрәҗәгать итмәгән кеше урынның өстенлекләрен куллана алмый.
23. Бу тугызның берсен генә булса да белмәгән кешенең гаскәре кыю идарәче гаскәре булалмас.
24. Әгәр дә кыю һәм сугышчан идарәченең гаскәре зур дәүләткә каршы чыкса, бу дәүләт көчен тупларга өлгермәс. Әгәр бу идарәченең көче дошманына каршы юнәлсә, дошман башкалар белән килешүләр дә төзи алмас.
25. Шуңа күрә бу идарәче Күк астында мондый шартнамәләрне бөтен кеше белән төзү артыннан кумый, Күк астындагы башка дәүләтне көчәйтергә җыенмый. Ул үз ихтыярын гына күрсәтә, дошманнарын куркыта, яшерен уйларын чынга ашарыа7 Шуңа күрә дә ул аларның кальгаларын яулый ала, дәүләтләрен тар-мар итә.
26. Гади кануннарга карамыйча, бүләкләр тарата, гадәти идарәдәге сыман кануннар чыгармый. Ул бер кеше белән идарә иткән сыман бөтен гаскәре белән дә идарә итә, диләр.

Син, гаскәреңдә хуҗа булганда, эшләр турында сөйлә, әмма җентекләп аңлатуга игътибар бирмә. Гаскәр белән идарә иткәндә, табыш турында сөйлә, зыян турында түгел.

27. Һәлакәтле урынга чыккач кына, сугышчыларың чын тормыш белән яши башлар; үлем урынына кергәч кенә, алар яшәүне аңлар; чып-чынлап бәлагә тарыгач кына алар сугышның ничек тәмамланасын хәл итәр.

28. Шуңа күрә сугыш алып баруның хикмәте — дошманыңа максатларына ярашлы рәвештш эшләргә мөмкинлек бир һәм аның артыннан күзәт; аннары бөтен игътибарны тупла һәм, ул хәтта мең чакрым ераклыкта булса да, дошманның сәргаскәрен үтер. Эшне сыйфатлы итеп башкару шушы була инде.

29. Яу башлыгы илтеп билгеләнүгә үк ил чикләрен яп, гамәлдәге ярлыкларны туктат, читтән илчелёр өчен ишекләрне юк ит.

Илбашы үз шурасында эшләп, идарә эшләре белән мавыгыр, ә сугыш өчен сәргаскәреннән генә сорар.

30. Дошманың капкаларны ача һәм яба башлаганда, кичекмәкстән җитез генә аңа бәреп керегез. Аңа кадерле булган нәрсәне тартып ал да, тыныч аны көт. Билгеләнгән юлдан бар, әмма дошманыңны эзәрлекләә. Шулай итеп син сугышны хәл итәрсең.

31. Шуңа күрә башта гаепсез саф бер кыз сыман бул — дошманың үзе сиңа капкаларын ачыр. Ә аннары йөгерек куянга әйлән — һәм дошманың сакланырга да өлгермәс.

12 НЧЕ БҮЛЕК. УТ БЕЛӘН ҺӨҖҮМ ИТҮ

Һөҗүм иткәндә утны куллану ысуллары

1. Сунь-цзы әйтте: ут белән һөҗүм итүнең төрләре биш: беренчесендә кешеләрне яндыралар; икенчесендә запасларга ут төртәләр; өченчесендә мал-мөлкәт яндырыла; дүртенчесендә келәтләр яна; бишенчесендә дошманга ут атырлар.
2. Ут белән гамәлләр башкарганда, аларның нигезле булуы шарт. Утлы чараларны алдан юнәтергә кирәк. Ут кабызыр өчен, тиешле вакытын билгелә; ут чакырыр өчен, тиешле көне дә кирәк. Дөрес вакыт — коры һава торышы булган вакыт; дөрес көн — ай Цзи, Би, И, Чжэнь йолдызлыкларында булган көннәр, чөнки ул көннәрдә җил еш исә.

Рәшә, Дивар, Канат һәм Арата йолдызлыклары — 28 йолдыз йортының 7нче, 14нче, 27нче һәм 28нчесе. Хәзерге Укчы, Пегас, Касә һәм Карга йолдызлыкларына өлешчә туры киләләр.

3. Әгәр һөҗүм вакытында ут куллансаң, менә нинди юллар барлыгын исеңдә тот.

1) Әгәр ут эчтә кабынса, мөмкин кадәр тизрәк аны тыштан да куәтләндереп тор.

2) Әгәр ут чыкса, әмма дошман гаскәре тыныч булса, ашыкма, һөҗүм итмә.

3) Ут иң куәтле мизгеленә җиткәч, аның артыннан бар, әгәр мөмкин булса инде; барып булмаса, урыныңда кал.

4) Әгәр утны тыштан кабызып булса, эчтә булганнарны көтмә, вакытны сайла да, төртеп җибәр.

5) Әгәр дә ут җил агымына уңайга кабынган икән, җил астыннан һөҗүм итмә. Көндезге җил озак исә, төнгесе тиз тына.

4. Гомумән, сугышта ут белән һөҗүм итүнең биш ысулы турында бел һәм бар чараларны кулланып, алардан сакланырга тырыш. Шуңа күрә дә һөҗүмнәренә ут белән дә булышкан кешеләр акыллы; һөҗүмнәренә су белән дә булышучылар гаскәрләрен көчәйтәләр. Әмма су белән дошманның бар нәрсәсен талап алып булмый.

Илбашы һәм сәргаскәр

Әгәр сугышырга һәм җиңәргә, һөҗүм итәргә һәм тартып алырга теләп тә, бу чараларга мөрәҗәгать итмәсәң, эшең харап булыр; «озакка сузылган чыгымнар» хасил булыр. Белемле илбашы бу чараларга өмет баглар, ә яхшы сәргаскәр аларны кулланыр.

Белемле илбашы планнарын алдан төзер; яхшы сәргаскәр мөмкинлекләрен арттырыр.

5. Әгәр дә өстенлек булмаса, хәрәкәтләнмә; әгәр берни дә яулый алмасаң, гаскәреңне эшкә җикмә; әгәр куркыныч янамаса, сугышма. Илбашы ачуы чыккан өчен генә коралланырга тиеш түгел; сәргаскәргә усаллыгы аркасындагы гына сугышка керергә ярамый. Табыш һәм отышка ярашлы булганда гына хәрәкәт башлана; әгәр бер табыш-файда да юк икән, урыныңда кал. Ачу һәм ярсу яңадан шатлык-сөенеч булып үзгәрергә, усаллыкны куаныч алыштырырга мөмкин, әмма бер җимерелгән дәүләт кире кайтмас, үлгәннәр терелмәс. Шуңа күрә дә акылла илбашы сугышка бик сак карый, ә яхшы сәргаскәр, гомумән, сугыштан читтә торырга тырыша. Нәкъ шушы юл белән син дәүләтеңне тынычлыкта, гаскәреңне иминлектә сакларсың.

13 НЧЕ БҮЛЕК. ШЫМЧЫЛАРНЫ КУЛЛАНУ

Сугышның бәясе

1. Сунь-цзы әйтте: йөз меңлек гаскәр җыеп, мең чакрымга яу чапканда, игенчеләрнең һәм илбашының чыгымнары көненә мең алтын тәңкә була. Илнең эчендә һәм тышында халык дулкынлана; җиде йөз мең гаилә юлдан талчыга һәм эшкә керешә алмый.
2. Берничә ел буена бер-береңнән саклансаң да, җиңүне бер көндә генә хәл итәләр. Мондый шартларда мактаулы исемнәр, бүләкләр һәм акчаларны кызгану һәм дошманның халәтен белмәү — кешелексезлек. Акча кызганып торган кеше сугышчыларның сәргаскәре, илбашының ярдәмчесе, җиңүнең хуҗасы була алмый.
3. Акыллы илбашлары һәм сәләтле сәргаскәрләр, барын да алдан күргәнгә күрә, курыкмыйча алга барганнар һәм җиңгәннәр, башкаларны уздырып, каһарманлыклар кылганнар.
4. Алдан күрер өчен иләһләр белән җеннәр дә булышмас, мантыйк һәм исәпләүләрнең дә файдасы булмас. Дошманның халәтен белер өчен бары кешеләр генә ярдәмгә килә ала.

Шымчыларның төрләре

5. Шуңа күрә шымчыларның биш төрлеләре була:

1) җирле шымчылар;
2) эчке шымчылар;
3) кире шымчылар;
4) үлем шымчылары;
5) яшәү шымчылары.

6. Шымчыларның биш төрлесе дә эшләгәндә аларның юлларын белеп булмый. Бу төшенеп булмый торган сер дип атала. Алар — илбашының хәзинәсе.

7. Җирле шымчыларны дошман иленең җирле халкы арасыннан яллыйлар һәм кулланалар; эчке шымчыларны түрәләр арасыннан яллыйлар һәм шулай кулланалар; кире шымчыларны дошман шымчылары арасыннан яллыйлар һәм аларны кулланалар. Әгәр мин берәр нәрсә эшләгән булып алдашырга теләсәм, бу хакта шымчыларыма хәбәр итәм, алар аны дошманга җиткерәләр. Бу шымчылар үлем шымчылары була. Яшәү шымчылары исә хәбәр белән исән кайта торган шымчылар була.

Үлем шымчыларын кулланганда, без үз шымчыларыбызга ялган хәбәр бирәбез һәм аларны тоту уңайлы булсын өчен шартлар корабыз. Алар дошман кулына эләккәч, ялган хәбәребезне чишәчәкләр, без исә үзебез теләгәнчә хәрәкәт кыла алырбыз. Ләкин бу шымчыларны дошман җәзалап үтерәчәк.

8. Шуңа күрә гаскәрдә шымчылардан да якынрак беркем юк; шымчыларга бүләктән зуррак бүләкләр дә юк; шымчы эшләреннән дә яшеренрәк, серлерәк булган бер эш тә юк.

Шымчыларны кулланганда сәргаскәргә ниләр кирәк

Белемең камил булмаса, аларның хезмәтеннән файдалана алмассың. Кешелеклек һәм гаделлегең булмаса, аларны кулланып булмас; зирәклек һәм үткенлектән башка шымчыларыңнан чын нәтиҗәне алалмассың. Үткенлек! Үткенлек! Шымчыларны һәр нәрсәдә кулланып була.

9. Әгәр шымчының хәбәре җибәрелгәнче үк чишелсә булса, шымчының үзен дә, серен чишкән кешесен дә үлемгә хөкем итәләр.
10. Гомумән, әгәр дошман гаскәренә һөҗүм итәсе, аның кальгасын җимерәсе, кешеләрен үтерәсе килсә, иң әүвәл яубашының, ярдәмчеләренең, сакчылар башлыгының һәм сакчыларның исемнәрен бел. Шымчыларыңа моны белергә куш.
11. Әгәр дә дошманың синең арттан күзәтер өчен шымчы җибәрсә, аңа табыш-файда белән тәэсир ит: үз яныңа керт һәм йортыңда урнаштыр. Шулай итеп синең кире шымчың барлыкка килер, син аны да куллана алырсың. Аның аша дошманың турында барын да белерсең. Шул рәвешле җирле һәм эчке шымчыларны да булдырып, алардан да файдалана алырсың. Аның аркылы барын да белеп барганга, син, берәр уйдырма уйлап чыгарып, үлем шымчыңа дошманның башын

әйләндерергә куша аласың. Аның аша барын да беләчәксең, һәм яшәү шымчыңа үз фаразларыңа карап эшләргә әмер бирә алачаксың.

12. Шымчыларның биш төрлесе белән дә илбашы үзе шөгыльләнә. Дошман турында нәкъ менә кире шымчы аркылы белгәнгә күрә, аның белән аеруча игътибарлы булырга кирәк.
13. Борынгы вакытларда, Инь патшалыгы әле күтәрелгәндә, Ся патшалыгында И Чжи бар иде; Чжоу күтәрелгәндә, Инь патшалыгында Люй Я булды.

Шуңа күрә бары тик гыйлемле илбашлары белән сәләтле сәргаскәрләр генә акыллы кешеләр арасыннан шымчылар яллап, шул ысул белән һичшиксез бөек гамәлләр кылалар. Шымчыларны куллану — сугышта иң мөһим нәрсә; һәр гаскәр шуңа таянып яши.

ЭЧТӘЛЕК

Сунь-цзы һәм аның «Сугыш сәнгате»..........3
1 нче бүлек. Сугыш алдыннан хисаплаулар..........5
2 нче бүлек. Сугыш алып бару..........8
3 нче бүлек. Стратегик һөҗүм..........10
4 нче бүлек. Хәрби тәртип..........13
5 нче бүлек. Көчләр..........15
6 нчы бүлек. Көчле вә зәгыйфь урыннар..........19
7 нче бүлек. Сугыштагы көрәш (маневрлар)..........23
8 нче бүлек. Тугыз үзгәреш..........26
9 нчы бүлек. Яуга чыккан гаскәр..........28
10 нчы бүлек. Урын-җир..........33
11 нче бүлек. Тугыз урын..........36
12 нче бүлек. Ут белән һөҗүм итү..........42
13 нче бүлек. Шымчыларны куллану..........44

Литературно-художественное издание

Сунь-цзы

ИСКУССТВО ВОЙНЫ

Перевод и составление: Айдар Шайхин

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

Сунь-цзы

СУГЫШ СӘНГАТЕ

Тәрҗемәче һәм туплаучы Айдар Шәйхин

Басарга кул куелды 25.07.2018. Формат 60х84/16. Шартлы басма бит 2,88.
Тираж 100 нөсхә. Заказ 544.

«Яңа нәшрият» нәшрияты. 420006, Казан ш., Татарстан ур., 2
«Бук» нәшриятында бастырылды.